МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.04.2020 Казан шәһәре № 221

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

**Боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2015 елның 19 мартындагы 135 номерлы, 2015 елның 28 июлендәге 346 номерлы, 2016 елның 2 июнендәге 177 номерлы, 2016 елның 6 декабрендәге 385 номерлы, 2019 елның 18 гыйнварындагы 23 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Дәүләт мәгълүмат ресурслары секторына әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны министр урынбасары А.Д.Шәмсиевка йөкләргә.

**Министр** **М.Р. Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
2020 елның 29 апрелендәге
221 номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2015 елның 19 мартындагы 135 номерлы, 2015 елның 28 июлендәге 346 номерлы, 2016 елның 2 июнендәге 177 номерлы, 2016 елның 6 декабрендәге 385 номерлы, 2019 елның 18 гыйнварындагы 23 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламентында:

2 бүлектә:

2.8 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кече эшкуарлык субъекты булып торган алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең бер резидентына карата план буенча күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты бер елга кече предприятие өчен кырык сәгатьтән һәм микропредприятиеләр өчен ун сәгатьтән артмаска тиеш. Тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларның дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак вакытлы махсус тикшерүләр һәм экспертизалар үткәрү зарурилыгы белән бәйле аерым очракларда тикшерү үткәрү вакыты озайтыла, ләкин кече предприятиеләргә карата – иң күбе утыз сәгатькә кадәр генә, микропредприятиеләргә карата – иң күбе ун сәгатьтән кадәр генә һәм алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең башка резидентларына карата – иң күбе унбиш эш көненә кадәр генә.»;

2.13 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2019 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәрге чорда үзләре турында белешмәләр кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законның 4 статьясындагы нигезләмәләргә ярашлы нигездә кече эшкуарлык субъектларына кертелгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата тикшерүләр 294-ФЗ номерлы федераль законның $26^2$ статьясындагы таләпләргә ярашлы рәвештә оештырыла һәм үткәрелә.»;

5 бүлектә:

5.27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.27. «Планнан тыш документар тикшерү уздыру» административ процедурасын башлау өчен әлеге Регламентның 2.15 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора, әгәр Россия Федерациясе норматив актларында башкасы каралмаган булса.»;

5.41 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.41. «Планнан тыш күчмә тикшерү уздыру» административ процедурасын башлау өчен әлеге Регламентның 2.15 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора, әгәр Россия Федерациясе норматив актларында башкасы каралмаган булса.

Күчмә тикшерү документар тикшерү барышында түбәндәгеләр мөмкин булмаган очракларда уздырыла:

1) лицензия алырга теләүченең, лицензиатның Министрлык карамагындагы документларындагы белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуына инану;

2) лицензия алырга теләүченең, лицензиат эшчәнлегенең лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен контрольлек буенча тиешле чара үткәрмичә бәяләү.».